**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 21 март № 167

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 гыйнвар, 25 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидияләр бирүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән төп эш итүче булып Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тора (алга таба – Министрлык).»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидияләр сайлап алуның түбәндәге критерияләренә җавап бирә торган юридик затларга бирелә:

чаралар оештыру һәм үткәрү;

килешү төзү планлаштырылган айга кадәрге айның беренче көненә:

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәү вакыты килеп җиткән салымнар, җыемнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмау;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетларына субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, кайтару буенча түләү вакыты чыккан бурычлары һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетларына бүтән түләү вакыты чыккан бурычлары булмау;

субсидия алучылар үзгәртеп төзү, бетерү, банкротлык процессында булмаса тиеш һәм хуҗалык эшчәнлеге алып баруда чикләүләре булмаска тиеш;

субсидия алучылар чит ил юридик затлары, шулай ук теркәлү урыны салым салуның ташламалы режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга мөнәсәбәттә финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүматны ачу һәм бирүне күздә тотмый торган (офшор зоналар) дәүләтләр һәм территорияләрнең Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган исемлегенә кертелгән дәүләтләр һәм территорияләр булган чит ил юридик затлары катнашу өлеше устав (тупланма) капиталларында тулаем алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик затлары булмаска тиеш;

субсидия алучылар әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алмаска тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.1 пункт өстәргә:

«5.1. Аларны каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнар исемлеге:

чаралар үткәрү өчен биналар һәм җиһазлар арендалауга чыгымнар;

канцелярия, хуҗалык товарлары, сувенир продукциясе сатып алуга чыгымнар;

стендны төзүгә һәм җиһазлауга (шул исәптән монтажлау-демонтажлау хезмәте күрсәтү, инженер-техник хезмәтләр күрсәтү) чыгымнар;

реклама-презентация материалларына һәм хезмәт күрсәтүләренә чыгымнар;

залларны бизәү, фотога һәм видеога төшерү хезмәтләре күрсәтүгә, чәчәкләр сатып алуга чыгымнар;

тәрҗемәче хезмәте күрсәтүләр өчен түләүгә чыгымнар;

концерт программасы өчен түләүгә чыгымнар;

транспорт хезмәтләре күрсәтүгә чыгымнар;

туклануны, экскурсия хезмәте күрсәтүне оештыруга чыгымнар;

ашыгыч медицина ярдәменең кизү бригадалары өчен түләүгә чыгымнар;

виза белән булышуга чыгымнар;

видеотрансляцияләр оештыруга һәм сайтлар төзүгә чыгымнар;

командировка чыгымнары;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы салым законнары нигезендә салымнар түләүгә.»;

6 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«чараны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнар булуны раслый торган документлар (башкарылган эшләр (күрсәтелгән хезмәтләр) актлары, йөкнамәләр һ.б.).»;

6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«субсидия бирү турында гариза тапшырылган көндә субсидия алучыга мөнәсәбәттә бетерү, банкротлык, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә аның эшчәнлеген туктатып тору процедуралары булмау турында субсидия алучы җитәкчелеге имза куйган гарантияле хат.»;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Юридик зат тапшырган документлар әлеге Тәртипнең 5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәгәндә яки әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмаганда (тулы күләмдә тапшырылмаганда) яки тапшырылган мәгълүмат дөрес булмаганда Министрлык хәбәр итү кәгазендә күрәтелгән вакыт узган көннән соң бер көн эчендә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.»;

түбәндәге эчтәлекле 15.1 пункт өстәргә:

«15.1. Субсидия күләме юридик зат тарафыннан заявка составында кушымтага ярашлы рәвештә субсидияләр күләмен исәпләү методикасы нигезендә нигезләнә.»;

17 пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия бирү турында килешүнең типик формасын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы раслый.

Субсидия бирү турында килешүдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар үткәрү белән бәйле чыгымнар төрләре, субсидияне күчерү тәртибе, субсидияне куллану турында хисап тапшыру тәртибе, вакытлары һәм формасы, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияне агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары, тәртибе һәм вакытлары, Министрлык һәм Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүләр үткәрүгә субсидия алучының ризалыгы (устав (җыелма) капиталларында гавәми-хокукый оешмалар катнашында дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр, хуҗалык иптәшлекләре һәм җәмгыятьләре, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый иптәшлекләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерциячел оешмалардан тыш), субсидия алучының әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәве турында нигезләмәләр, килешү шартларын бозган өчен җаваплылык күздә тотыла.»;

18 пунктта «килешүләр төзегән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 14 көн эчендә» сүзләрен «субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң унынчы эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

20 пунктның беренче, икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Министрлык һәм Финанс министрлыгы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча субсидия алучылар тарафыннан субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшырылган, субсидия бирү шартлары бозылу

очраклары билгеле булганда, субсидиядән файдалану турында хисап тапшырылмаган, хисап тапшыру вакытлары бозылган, субсидия акчасын максатчан кулланмау билгеле булганда Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә субсидияләр субсидия алучылар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

«Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен субсидия күләмен исәпләү методикасы

1. Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен субсидия күләмен исәпләү сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында, башка һәркем алырлык мәгълүмат чыганакларында урнаштырылган шундый ук контрактларны, шул исәптән мәгълүмат-бәя агентлыклары мәгълүматларын, базарны өйрәнүнең һәркем өчен ачык нәтиҗәләрен анализлау юлы белән, шулай ук чит ил делегацияләрен, чит илдән булмаган делегацияләрне, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән аерым затларны кабул итү һәм аларга хезмәт күрсәтүгә акча тоту нормаларын исәпкә алып планлаштырыла торган чыгымнар суммасы буларак субсидия күләмен билгеләүдән гыйбарәт.

2. Чыгымнарны билгеләгәндә «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 5.1 пунктында күрсәтелгән чыгымнар исәпкә алына.

3. Һәр чара буенча чыгымнар базар бәяләрен чагыштырып карау ысулы (базар анализы) белән билгеләнә. Һәр чара буенча чыгымнар суммасын нигезләү өчен юридик зат әлеге методикага өстәмә рәвештә мәгълүматлары ачык булган шундый өч контракт буенча материаллар тапшыра.

4. Субсидия күләмен исәпләү нәтиҗәләре түбәндәгечә билгеләнә (бу чакта һәр чара буенча чыгымнарны детальләштерү чыгымнар сметасы нигезендә билгеләнә):

| Эшләрнең (хезмәт күрсәтүләрнең) эчтәлеге | Эшләрнең (хезмәт күрсәтүләрнең) бәясе, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1 нче чара | |
| 2 нче чара | |
| 3 нче чара | |
| 4 нче чара | |
| 5 нче чара | |
| ... нчы чара | |
| Чараларны үткәрүнең гомуми планлаштырыла торган бәясе үз эченә ала | |
| чара үткәрү өчен урынны һәм җиһазларны арендалауга чыгымнар | |
| канцелярия, хуҗалык товарлары, сувенир продукциясе сатып алуга чыгымнар | |
| стенд төзүгә һәм җиһазлауга чыгымнар (шул исәптән монтажлау-ремонтлау хезмәтләре, инженер-техник хезмәтләр) | |
| реклама-презентация материалларына һәм хезмәтләренә чыгымнар | |
| залларны формалаштыру, фото- һәм видеотөшерү хезмәтләренә, чәчәкләр сатып алуга чыгымнар | |
| тәрҗемәчеләр хезмәтләре өчен түләүгә чыгымнар | |
| концерт программасы өчен түләүгә чыгымнар | |
| транспорт хезмәтләренә чыгымнар | |
| туклануны тәэмин итү, экскурсия хезмәте күрсәтүгә чыгымнар | |
| ашыгыч медицина ярдәме бригадалары кизү торуы өчен түләүгә чыгымнар | |
| виза ярдәме өчен түләүгә чыгымнар | |
| видеотрансляцияләр оештыруга һәм сайтлар ясауга чыгымнар | |
| командировка чыгымнары, әмма субсидия күләменең 5 процентыннан артык түгел | |
| Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә салымнар түләүгә | |
| Субсидиянең исәпләнгән күләме.». | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков